**СОВЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы,423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы Советының
КАРАРЫ

Башкарма комитеттан бухгалтер штат берәмлеген кабул итү турында

2022 елның 28 февраленнән №19-139

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законны нигезендә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Акбүре авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлегенә бухгалтер штат берәмлеген тапшыру турындагы тәкъдимен кабул итәргә 2022 елның 1 апреленнән.

2. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетына бухгалтер штат берәмлеген кабул итү һәм аны «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы казна һәм бюджет учреждениеләренә хезмәт күрсәтү үзәге» муниципаль казна учреждениесенә тапшыру вәкаләтләрен бирергә.

3. «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы казна һәм бюджет учреждениеләренә хезмәт күрсәтү үзәге» муниципаль казна учреждениесенә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Акбүре авыл җирлеге башкарма комитеты белән бухгалтерлык хезмәте күрсәтү буенча килешү төзергә.

4. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Финанс-бюджет палатасының әлеге карарын тормышка ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2021 елның 9 декабрендәге16-121 номерлы карары белән расланган «2022 елга, 2023 һәм 2024 еллар план чорына Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы

бюджеты турында»гы карарына үзгәрешләр кертү турындагы карар проектын бюджет законнары нигезендә карап тикшерүгә тәкъдим итәргә.

5. Әлеге карарны Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http://novosheshminsk.tatarstan.ru/ бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә районы Советының законлылык, хокук тәртибе һәм җирлекләрнең вәкиллекле органнары белән хезмәттәшлек буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Яңа Чишмә муниципаль районы Башлыгы В. М. Козлов